# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
17 апреля 2017 года

**Статья 1**

Статью 14 Закона Республики Татарстан от 8 июля 1992 года № 1560-XII «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 44-ЗРТ) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1992, № 6; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2012, № 3; 2014, № 6 (II часть) дополнить частями пятой и шестой следующего содержания:

«Свидетельство о государственной регистрации акта гражданского состояния оформляется на русском языке и содержит сведения о государственной регистрации акта гражданского состояния на татарском языке.

Сведения о государственной регистрации акта гражданского состояния на татарском языке, с применением которых оформляются свидетельства о государственной регистрации акта гражданского состояния, определяются Кабинетом Министров Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 30 декабря 2005 года № 146-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления в Республике Татарстан полномочиями на государственную регистрацию актов гражданского состояния» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 12 (IV часть); 2007,

№ 1 (I часть), № 11; 2008, № 10 (I часть); 2010, № 7 (II часть); 2011, № 5; 2013, № 10; 2016, № 5) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 2 изложить в следующей редакции:

«2. Субвенции на осуществление органами местного самоуправления переданных им полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния предоставляются местным бюджетам из бюджета Республики Татарстан в соответствии с Методикой расчета общего объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния, согласно приложению 1 к настоящему Закону.»;

2) часть 3 статьи 2 признать утратившей силу;

3) в абзаце третьем части 2 статьи 4 слова «первые и вторые экземпляры записей актов гражданского состояния» заменить словами «записи актов гражданского состояния на бумажных носителях»;

4) в статье 6:

а) в части 1 слова «, бланками записей актов гражданского состояния» исключить;

б) в части 2 слова «, бланками записей актов гражданского состояния» исключить;

5) в статье 7:

а) в наименовании слова «первых экземпляров» исключить, после слов «гражданского состояния» дополнить словами «на бумажных носителях»;

б) в части 1 слова «Первые экземпляры записей актов гражданского состояния» заменить словами «Записи актов гражданского состояния на бумажных носителях»;

6) статью $7^1$ признать утратившей силу.

**Статья 3**

Признать утратившим силу Закон Республики Татарстан от 7 мая 2016 года № 27-ЗРТ «О внесении изменения в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления в Республике Татарстан полномочиями на государственную регистрацию актов гражданского состояния» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2016, № 5).

**Статья 4**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2018 года, за исключением пунктов 1, 2 статьи 2 настоящего Закона.

2. Пункты 1, 2 статьи 2 настоящего Закона вступают в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань,Кремль
27 апреля 2017 года
№ 27-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 17 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2012, № 3; 2014 № 6 (II өлеш) түбәндәге эчтәлекле бишенче һәм алтынчы өлешләр өстәргә:

«Граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык рус телендә тутырыла, анда граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу турында татар телендә белешмәләр була.

Граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкны тутырганда кулланыла торган граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу турындагы татар телендәге белешмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10; 2016, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләрне алар тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр әлеге Законга 1 нче кушымтада каралган Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләү методикасы нигезендә бирелә.»;

2) 2 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4 статьяның 2 өлешендәге өченче абзацында «граждан хәле актлары язмаларының беренче һәм икенче нөсхәләрен» сүзләрен «граждан хәле актлары язмаларының кәгазь вариантларын» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 статьяда:

а) 1 өлештә «, граждан хәле актларын язу бланклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «, граждан хәле актларын язу бланклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 7 статьяда:

а) исемендә «Граждан хәле актлары язмаларының беренче нөсхәләрен» сүзләрен «Граждан хәле актлары язмаларының кәгазь вариантларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «төзелгән граждан хәле актлары язмаларының беренче нөсхәләре» сүзләрен «тутырылган граждан хәле актлары язмаларының кәгазь вариантлары» сүзләренә алмаштырырга;

6) $7^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2016 елның 7 маендагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 5) үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

1. Әлеге Закон, аның 2 статьясындагы 1, 2 пунктларыннан тыш, 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 1, 2 пунктлары бу Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2017 ел, 27 апрель
№ 27-ТРЗ